ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.02.2021 г. № 137

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 333 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләти җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.36 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль милектә булган җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 333 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

«Яшелчә, җиләк-җимеш һәм карбыз-кавын культураларын ваклап сату» бүлегендә 1, 2, 6, 7, 8, 9, 10, 11, 12, 13, 14, 15, 16, 17, 19, 20, 21, 22, 23, 24 пунктларын төшереп калдырырга;

«Поп-корн, татлы мамык, карамельле алма, кукуруз, туңдырма һ.б.ны ваклап сату» бүлегендә 1 пунктны төшереп калдырырга;

«Җәйге кафе» бүлегендә 3 пунктны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 21 апреленнән барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә кагыла.

3. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 апрелендәге 252 номерлы «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2018 елның 27 апрелендәге 333 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.И. Беляевка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы,
җитәкченең беренче урынбасары Р.И. Беляев